УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

«15» июля 2015 ел

№ 01-15/130-пр

**Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсенә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализ ясау тәртибе Нигезләмәсен раслау хакында**

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы закончылыкны үтәү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча бердәм тәртибен булдыру күзлегеннән чыгып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсенә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализ ясау тәртибе Нигезләмәсен расларга.
2. Бүлек башлыкларына һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен караучы затларга әлеге Нигезләмәгә таянып эшләргә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык вазыйфаларын вакытлыча башкаручы — М.А.Халиков

№ 1 Кушымта
Татарстан Республикасының
Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсе
15.07.2015 01-15/130-пр номерлы
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсенә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализ ясау тәртибе хакында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсенә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализ ясау тәртибе (алга таба – Тәртип) "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясын һәм «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү максаты белән эшләнде.

1.2. Нигезләмә, гражданнар мөрәҗәгатьләре килүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында, Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсенә (алга таба – Идарә) килгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау тәртибен билгели.

## II. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе

2.1. Гражданның мөрәҗәгате - гражданның дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына язма яисә электрон документ рәвешендә бәян ителгән тәкъдиме, гаризасы яисә шикаяте, шулай ук дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына телдән мөрәҗәгате.

2.2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен караганда мөрәҗәгать итүче ризалыгыннан башка аның шәхси тормышы турындагы белешмәләрне куллану һәм тарату тыела. Компетенциясенә мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү керә торган органга яисә вазыйфаи затка язмача мөрәҗәгатьне җибәрү, мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне фаш итү дип саналмый.

2.3. Идарәгә килгән мөрәҗәгатьләр, кергән мизгелдән өч көн эчендә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

2.4. Язмача мөрәҗәгатькә аны җибәргән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы- булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле почта

адресы, сорауның асылын бәян итү, язылу датасы һәм шәхси имзасы мәҗбүри куелырга тиеш.

Граждан дәлилләрне раслаучы кирәкле документларны һәм материалларны язмача мөрәҗәгатькә кушып бирергә яисә аларның күчермәләрен куя ала.

Электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгатьтә граждан фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), әгәр җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, электрон почта адресы, әгәр җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булса, почта адресы күрсәтелергә тиеш.

Язмача мөрәҗәгатьтә, аны җибәргән гражданның фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле адресы күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми.

2.5. Язмача мөрәҗәгать тексты укырлык булмаган очракта яисә мөрәҗәгать әдәпсез сүзләр яисә түбәнсетү тәгъбирләре, вазыйфаи зат тормышына, сәламәтлегенә яисә мөлкәтенә, шулай ук аның гаилә әгъзаларына куркыныч янау турында бирелсә, Идарә башлыгы түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

әгәр гражданның фамилиясен һәм почта адресын укып булганда, мөрәҗәгатьне укып булмау һәм башка дәүләт органнарына җибәрә алмау сәбәпле, гражданга аның мөрәҗәгатенең кире кайтарылуы, шулай ук кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы булуын аңлатып хәбәр итү турында;

гражданга закон тарафыннан бирелгән мөрәҗәгать итү хокукын чамасын белеп кенә кулланырга кирәклеге турында хәбәр итеп, мөрәҗәгатьне җавапсыз калдыру турында;

граждан турындагы мәгълүматне укып булмаса (фамилия һәм адрес), мөрәҗәгать Идарә җитәкчелеге белән килештерелеп, оештыру-хокук бүлеге башлыгы тарафыннан, мөрәҗәгать бирүчегә бу турыда хәбәр ителмичә, алып куела.

2.6. Мөрәҗәгатьне җавапсыз яки карап тикшерүсез калдыру турындагы карар Идарә башлыгы тарафыннан эш башкаручы әзерләгән рәсми язу буенча кабул ителә һәм оештыру-хокук бүлегенә җибәрелә.

2.7. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауның асылы буенча җавап федераль закон белән саклanучы дәүләт серен һәм башка серне тәшкил итә торган белешмәләрне фаш итүдән башка бирелә алмаса, мөрәҗәгатьне юллаган гражданга күрсәтелгән белешмәләрне фаш итүнең ярамаганлыгына бәйле рәвештә мөрәҗәгатьтә куелган сорауның асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмавы турында хәбәр ителә.

2.8. Идарәгә килгән мөрәҗәгатьләр мәҗбүри тикшереп каралырга тиеш. Алдан тикшереп карау нәтиҗәсе буенча Идарә башлыгы тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителергә тиеш:

карап тикшерергә кабул итү турында;

карап тикшерүсез калдыру турында;

башка органнарга җибәрелүе турында;

мөрәҗәгатьне карап тикшерүне туктату турында;

алдарак кергән мөрәҗәгатькә кушып куярга;

мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару турында.

2.9. Мөрәҗәгатьне карап тикшерү Идарә компетенциясенә кермәгән очракта, теркәгән көннән алып җиде көн эчендә, мөрәҗәгать бирүчегә шул хакта хәбәр итеп, тиешле компетентлы органнарга юллана.

2.10. Мөрәҗәгатьне вакытында карап тикшерү объектив сәбәпләр аркасында мөмкин булмаган очракта, мөрәҗәгатьне карап тикшерү срогы тәгәлләнүгә кимендә биш көн кала, аны карап тикшерү срогын озайту турындагы рәсми язу йөкләмә биргән вазыйфаи затка җибәрелә.

## III. Гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау

3.1. Идарәгә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэмин итү бүлекчәсенең (алга таба – бүлекчә) җаваплы белгече тарафыннан ярты ел һәм ел йомгаклары нигезендә башкарыла.

3.1. Идарәгә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ бүлекчәнең җаваплы белгече тарафыннан "Электрон Хөкүмәт" Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документлар системасын кулланып ясала.

3.2. Идарәгә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсенең рәсми сайтында "Гражданнар мөрәҗәгатьләре" бүлегенен "Гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча хисаплар" бүлекчәсендә хисап чорыннан соң килүче айның 22 числосыннан да соңламый урнаштырыла.

3.3. Идарәгә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләре нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэмин итү бүлекчәсенең белгече тарафыннан аналитик белешмә (мәгълүмат) төзелә.

3.4. Аналитик белешмә (мәгълүмат) түбәндәге мәгълүматтан торырга тиеш (хисап чоры өчен):

кабул ителгән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны;

электрон документ формасында һәм Интернет кабул итү бүлмәсе аша кабул ителгән, бүтән адрес белән җибәрелгән, карап тикшерелгән мөрәҗәгатьләр саны;

кабул ителгән, бүтән адрес белән җибәрелгән, карап тикшерелгән язма мөрәҗәгатьләр саны;

шәхси кабул ителгән гражданнар саны;

гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре;

гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле вазыйфаи затлар һәм урынга чыгып шәхси кабул итү;

мөрәҗәгатьләр тематикасы;

мөрәҗәгатьләрне тикшереп караганнан соң күрелгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән хокукый норматив һәм башка төрле актларны кабул итү турында мәгълүмат (булган очракта).

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Әлеге Тәртипкә кертелә торган барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Идарә башлыгы боерыгы белән расланалар.